# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Алга авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14.11.2025 ел** **№ 1**

« Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Алга авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турындагы" карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендә 8.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Алга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, юлларны кардан чистарту, үлән чабу, юлга таш җәю);

3) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру) ?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _51 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - _31_ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 31__катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен __0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Алга авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2«Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Алга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, юлларны кардан чистарту, үлән чабу, юлга таш җәю);

3) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру) ?

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина